РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШЕТНЕВО-ТУЛУШСКОГО сельского поселения Рыбно-Слободского муниципального района**
**422644, с.Шетнево-Тулуши**
ул.М.Джалиля, д.18,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Балык Бистәсе муниципаль районы ЮГАРЫ ЫРГА авыл җирлегенең БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**422644, Шетнево-Тулуш,**
М.Җәлил урамы, 18.

Тел.: (884 361) 27-451, факс: (884 361) 27-451. электронный адресl: Stul.Rs@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2024 Югары Ырга авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законына, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарына тәңгәлләштереп, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 һәм 2 кушымтада күрсәтелгәнчә 8 370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм 2024 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварында кабул ителгән “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында”гы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Югары Ырга авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 йорт, адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Багаутдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Югары Ырга авыл
җирлеге Башкарма комитетының
22.01.2024 елның 1 номерлы карарына
кушымта 1

**2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5929,46 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 841,19 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 1599,55 |
| Җәмгысе: | **8370,20** |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Югары Ырга авыл
җирлеге Башкарма комитетының
22.01.2024 елның 1 номерлы карарына
кушымта 2

**2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 2963,06 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2963,06 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 836,22 |

| | |
|---|---|
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1607,86 |
| Җәмгысе: | **8370,20** |